СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.06.2025 №6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Янурыс авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.25 маддәсенең 9 пунктында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының 25.11.2022 ел № 20 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре» нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8.2 пунктның 1 абзацы. VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "8.2. Хуҗалык итүче субъектлар һәм физик затлар, әгәр законда яки шартнамәдә башкасы каралмаган булса, янәшәдәге территорияне җыештыруда һәм санитар тотуда, шул исәптән финанс яктан да, түбәндәге тәртиптә катнашырга тиеш:»

2) 9.4 Пункт. IV бүлекне төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге
Совет рәисе

А.Ә.Мөхәмәдиева